РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март 2024 ел Буа шәһәре № 6-59

ТР Буа муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы, һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» 2017елның 6 июлендәге 5-22 номерлы карары белән расланган ТР Буа муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлектә;

5.9 пунктының 5.9.6 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«5.9.6. «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен бина хуҗаларының күпфатирлы йорттагы гомуми милке кулланылган очракта 5 өлештә билгеләнгән таләпләрне бозу.»;

5.12. пуктның 5.12.1. пунктчасын «хәбәрнамә» сүзләренән соң «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып, язма рәвештә яки электрон документ формасында» сүзләре белән тулыландырырга;

5.12. пунктының 5.12.5. пунктчасын «5.1, 5.6, 5.7 өлешләре белән» сүзләрен «5 нче өлеш, әгәр реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күп фатирлы йортта бина хуҗаларының гомуми милке кулланылса, 5.1, 5.6, 5.7 өлешләре белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов